| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>НОВОИЛЬМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯҢА ӘЛМӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Яңа Әлмәле авылы

2023 елның 18 декабрь №21

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлеге территориясендә гражданнарга беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 1978 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлеге Уставына таянып:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлеге Башлыгың 18.09.2023 ел №14 “Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлеге территориясендә гражданнарга беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында” гы карарның 1 бүлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1)5 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Яшәү урыны яисә булу урыны буенча гражданнарның персональ хәрби исәпкә алуы (3 айдан артык вакытка), шул исәптән яшәү урыны һәм (яисә) булу урыны буенча, яисә альтернатив граждан хезмәте узу урыны яисә иректән мәхрүм итү рәвешендәге җәзаны үтәү муниципаль берәмлекләрнең хәрби комиссариатлары (алга таба - хәрби комиссариатлар) тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

**2) 8 пунктта:**

**а) «а» пунктчасында** «27 яшь» сүзләрен «30 яшь» сүзләренә алмаштырырга;

**б) «б» пунктчасының 7-9 абзацларында** «27 яшь» сүзләрен «30 яшь» сүзләренә алмаштырырга.

**3) 9 пунктның «в» пунктчасын** төшереп калдырырга**.**

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә.

Татарстан республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Әлмәле авыл җирлеге башлыгы: Р.Н. Дружков